**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 сентябрь № 677

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 декабрь, 985 нче, 2015 ел, 20 март, 179 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт программасы
ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Дәүләт программасы исеме | «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» (алга таба – Программа) |
| Программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;<br>«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе |
| Программаның максатлары | Татарстан Республикасы халкын һәркем сатып алырлык һәм сыйфатлы торак белән тәэмин итү;<br>торак фондның энергия нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын, халыкның коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителү дәрәҗәсен, коммуналь хезмәт күрсәтүләрнең ышанычлылыгын һәм сыйфатын күтәрү |
| Программаның бурычлары | Торак сатып алганда һәм торак шартларын яхшыртканда гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәләрен һәм социаль гарантияләрне үтәү;<br>торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар формалаштыру, шул исәптән нәтиҗәле файдаланылмый торган федераль җирләрне әйләнешкә кертү һәм территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә;<br>гражданнар яшәве өчен имин һәм уңай шартлар тудыру;<br>халыкны билгеләнгән санитария-эпидемиология кагыйдә- |

| | |
|---|---|
| | ләренә туры килүче эчә торган чиста су белән тәэмин итү;<br>коммуналь системаларның ышанычлы булуына һәм ресурсларны нәтиҗәле тотуга ирешү;<br>торак-коммуналь хуҗалыкның энергия нәтиҗәлелеген күтәрү;<br>архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыру |
| Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2020 еллар.<br>I этап: 2014 – 2016 еллар;<br>II этап: 2017 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | «2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»;<br>«2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларны торак урыннар белән тәэмин итү»;<br>«2014 – 2015 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру»;<br>«2014 – 2017 елларда гражданнарны авария хәлендәге торак фондтан күчерү буенча адреслы республика программасы чараларын тормышка ашыру»;<br>«2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программа чараларын тормышка ашыру»;<br>«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын су һәм җылылык белән тәэмин итү хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итүне яхшырту»;<br>«2015 – 2020 елларга торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү»;<br>«2014 – 2020 елларга архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтен тормышка ашыру» |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 41 822 943,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: |

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | федераль бюджет | Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды | Татарстан Республикасы бюджеты | җирле бюджетлар | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 653839,3 | 15 597,7 | 1 7 870,6 | 2203224,4 | 1072210,0 | 2148936,6 |
| 2015 | 7812354,1 | 89110,4 | 1270032,2 | 3174448,6 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2016 | 6386855,1 | 88531,5 | 1096232,0 | 2002328,7 | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2017 | 5662114,0 | 87487,7 | 350734,0 | 2024129,6 | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2018 | 4986399,9 | - | - | 1786637,0 | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2019 | 5003074,0 | - | - | 1803311,1 | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2020 | 5018306,4 | - | - | 1818543,5 | 1072931,0 | 2126831,9 |
| Барлыгы | 41822943,0 | 416727,3 | 4094868,8 | 14812622,9 | 7509796,0 | 14988928,1 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш

| | |
|---|---|
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тормышка ашыру 2016 ел ахырына түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>949 ятим баланы һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларны торак урыннар белән тәэмин итүгә;<br>100 яшь гаиләнең торак шартларын яхшыртуга;<br>торак фондының гомуми күләмендә искергән һәм авария хәлендәге торак фонды өлешен 1,1 процентка кадәр киметүгә.<br>2021 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Татарстан Республикасының уртача бер кешесенә туры килә торган торак урыннар гомуми мәйданын 27,3 метрга кадәр арттыруга;<br>зыянга эшләүче торак-коммуналь хуҗалык оешмалары өлешен 9 процентка кадәр киметүгә;<br>Татарстан Республикасы торак фондының гомуми мәйданында барлык төр уңайлыклар белән тәэмин ителгән торак фонды мәйданы өлешен 76 процентка кадәр арттыруга;<br>бер яшәүчегә елына салкын су куллануның чагыштырма зурлыгын 35,1 куб.метрга кадәр, кайнар су куллануның чагыштырма зурлыгын 16,8 куб.метрга кадәр, җылылык энергиясен елына 1 кв.метр мәйданга 0,2 Гкал кадәр киметүгә;<br>җылылык энергиясен тапшырганда югалтылган өлешен |

| | |
|---|---|
| | тапшырылган энергиянең гомуми күләмендә 12,6 процентка кадәр киметүгә;<br>суны тапшырганда югалтылган өлешен тапшырылган суның гомуми күләмендә 15,8 процентка кадәр киметүгә»; |

1 бүлекнең 1.2 пунктындагы унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республикада Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм районнарында фатирлап җылыту системасына күчү һәм чыгырлы-модульле казаннар урнаштыру буенча программа гамәлдә, ул республиканың лизинг фонды акчасы исәбеннән финанслана.»;

2 бүлектә:

егерме сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле утыз – утыз икенче абзацлар өстәргә:

«бер яшәүчегә елына салкын су куллануның чагыштырма зурлыгын 35,1 куб.метрга кадәр, кайнар су куллануның чагыштырма зурлыгын 16,8 куб.метрга кадәр, җылылык энергиясен елына 1 кв.метр мәйданга 0,2 Гкал.га кадәр киметү;

җылылык энергиясен тапшырганда югалтылган өлешен тапшырылган энергиянең гомуми күләмендә 12,6 процентка кадәр киметү;

суны тапшырганда югалтылган өлешен тапшырылган суның гомуми күләмендә 15,8 процентка кадәр киметү.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.7^1$ пункт өстәргә:

«$2.7^1$. «2015 – 2020 елларга торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» ярдәмче программасы.

Ярдәмче программа максаты – торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү.

Ярдәмче программа бурычлары:

торак фондында энергетика ресурслары һәм су куллануны киметү;

энергетика ресурслары һәм су җитештергәндә (тапшырганда) энергия саклауны тәэмин итү.

Ярдәмче программа чаралары түбәндәгеләргә булышлык итәчәк:

Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгында энергетика нәтиҗәлелеген күтәрүгә;

кулланылган энергетика ресурсларына һәм суга чыгымнарны киметүгә.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү фаразы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет, Дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2014 – 2020 елларда Программаны финанслауның фаразлана торган гомуми күләме 41 822 943,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты | Җәлеп итергә планлаштырылган акча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | федераль бюджет | Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды | җирле бюджетлар | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 6953839,3 | 2203224,4 | 151597,7 | 1377870,6 | 1072210,0 | 2148936,6 |
| 2015 | 7812354,1 | 3174448,6 | 89110,4 | 1270032,2 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2016 | 6386855,1 | 2002328,7 | 88531,5 | 1096232,0 | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2017 | 5662114,2 | 2024129,6 | 87487,7 | 350734,0 | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2018 | 4986399,9 | 1786637,0 | - | - | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2019 | 5003074,0 | 1803311,1 | - | - | 1072931,0 | 2126831,9 |
| 2020 | 5018306,4 | 1818543,5 | - | - | 1072931,0 | 2126831,9 |
| Барлыгы | 41822943,0 | 14812622,9 | 416727,3 | 4094868,8 | 7509796,0 | 14988928,1 |

Программа юнәлешләре буенча финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләреннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Барлык чыганаклар исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм Программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының фараз кыйммәте бу Программага теркәлгән кушымтада китерелә.»;

Программага кушымтада:

«Су белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгына һәм ресурслары нәтиҗәлелегенә ирешү» юлында:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Су белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгына һәм ресурслары нәтиҗәлелегенә ирешү | | | Коммуналь инфраструктураның тузу дәрәҗәсе, % | 47,7 | 47,6 | 47,5 | 47,4 | 47,3 | 47,2 | 47,1 | 47 | | | | | | | »; |

«Авыл халкын аварияләрсез, өзлексез ягулык белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итү чыганаклары белән тәэмин итү» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме: «2015 – 2020 елларга торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Торак фондында энергетика ресурс-лары һәм су куллануны киметү | ТР ТАТКХС, ТР ChСМ, ГФ, ҖҮО | 2015 – 2020 | Күпфатирлы йортларда салкын суны чагыштыр-мача куллану, 1 кешегә куб.метр | - | 36,5 | 36,3 | 36,1 | 35,9 | 35,7 | 35,5 | 35,1 | - | 686565,5 ТРБ | 686565,5 ТРБ | 686565,5 ТРБ | 686565,5 ТРБ | 686565,5 ТРБ | 686565,5 ТРБ |
| | | | Күпфатирлы йортларда кайнар суны чагыштыр-мача куллану, 1 кешегә куб.метр | - | 18,2 | 18,0 | 17,7 | 17,5 | 17,3 | 17,0 | 16,8 | | | | | | | |
| | | | Күпфатирлы йортларда җылылык энергиясен чагыштырмача куллану, гомуми мәйданның гкал/кв.метр | - | 0,21 | 0,21 | 0,205 | 0,205 | 0,203 | 0,201 | 0,20 | | | | | | | |
| Энергетика ресурс-лары һәм су җитештергәндә (тап-шырганда) энергия саклауны тәэмин итү | | | Тапшырылган җылылык энергиясенең гомуми күләмендә җылылык энергиясен тапшырганда аның югалтылган өлеше, % | - | 13,4 | 13,2 | 13 | 12,9 | 12,8 | 12,7 | 12,6 | - | 294900,0 ТРБ | * | * | * | * | *»; |
| | | | Тапшырылган суның гомуми күләмендә суны тапшырганда аның югалтылган өлеше, % | - | 16,3 | 16,2 | 16,1 | 16 | 15,9 | 15,9 | 15,8 | | | | | | | |

«Архитектура, шәһәр төзелеше, гражданнар һәм сәнәгать төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының гомумпрограмма эшчәнлеге» юлында «Коммуналь инфраструктураның тузу дәрәҗәсе, %» ярдәмче юлын төшереп калдырырга;

«Дәүләт программасы буенча барысы, шул исәптән:» һәм «Татарстан Республикасы бюджеты» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Дәүләт программасы буенча барысы, шул исәптән: | 6953839,3 | 7812354,1 | 6386855,1 | 5662114,2 | 4986399,9 | 5003074,0 | 5018306,4 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 2203224,4 | 3174448,6 | 2002328,7 | 2024129,6 | 1786637,0 | 1803311,1 | 1818543,5»; |

файдаланылган кыскартулар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ТР СһСМ – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ГФ – «Татарстан Республикасы Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженер челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждение-се»;

«2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасында:

күрсәтелгән ярдәмче программага 5 нче кушымтада 11 пунктта «оешма мөһере белән расланган» сүзләреннән соң «, (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә;

Программага «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын су һәм җылылык белән тәэмин итү хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итүне яхшырту» ярдәмче программасыннан соң кушымта нигезендәге редакциядә «2015 – 2020 елларга торак-коммуналь хуҗалыкта энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» ярдәмче программасын өстәргә;

«2014 – 2020 елларга архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтен тормышка ашыру» ярдәмче программасында:

күрсәтелгән ярдәмче программа паспортында «Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында түбәндәге эчтәлекле абзацны төшереп калдырырга:

«бер яшәүчегә елына салкын су куллануның чагыштырма зурлыгын 36,6 куб.метрга кадәр, кайнар су куллануның чагыштырма зурлыгын 17,2 куб.метрга кадәр, җылылык энергиясен елына 1 кв.метр мәйданга 0,2 Гкал.га кадәр киметү;»;

2 бүлектә унсигезенче абзацны төшереп калдырырга;

ярдәмче программага кушымтада:

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының архитектура, шәһәр төзелеше, гражданнар һәм сәнәгать төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гомумпрограмма эшчәнлеге»

юлында түбәндәге ярдәмче юлларны төшереп калдырырга:

«Коммуналь инфраструктураның тузу дәрәҗәсе, %»;

«Күпфатирлы йортларда җылылык энергиясен куллануның чагыштырма зурлыгы, елына 1 кв.метр мәйданга»;

«Күпфатирлы йортларда кайнар суны куллануның чагыштырма зурлыгы, елына 1 яшәүчегә куб.метр»;

«Күпфатирлы йортларда салкын суны куллануның чагыштырма зурлыгы, елына 1 яшәүчегә куб.метр».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\677.docx